ГЛАВА
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.02.2026 г.Мензелинск № 7

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башлыгының 2022 елның 26 августындагы "Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында Нигезләмәне раслау турында" №34 карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2026 елның 19 гыйнварындагы «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» №7 Карары нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башлыгы КАРАР ЧЫГАРА:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башлыгының 2022 елның 26 августындагы «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында Нигезләмәне раслау турында» №34 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 нче пунктында «хәрби конфликтлар вакытында яки шул конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, хәрби вакытта» сүзләре белән алыштырырга;

1.2. Нигезләмәнең 15.6 пунктының 2 абзацында «оборонаны һәм» сүзләрен «оборонаны, тәэмин итү һәм кирәк булган көчләрне әзерләү» сүзләре белән алыштырырга;

1.3. Нигезләмәнең 15.7 пунктының 1 абзацында «хәрби конфликтлар вакытында яки шул конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл вакытында, хәрби вакытта килеп чыккан куркынычлык нәтиҗәсендә» сүзләре белән алыштырырга.

1.4. Нигезләмәнең 15.7 пунктының 4 абзацын гамәлдән чыгарылган дип танырга;

1.5. Нигезләмәнең 15.7 пунктының 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мобилизация чорында, хәрби хәл вакытында, сугыш вакытында килеп чыккан куркынычлык нәтиҗәсендә зыян күргән халык арасында санитар-гигиена һәм эпидемиягә каршы чаралар үткәрү;»

1.6. Нигезләмәнең 15.7 пунктының 12 абзацында «ял йортларында, пансионатларда һәм башка сәламәтләндерү учреждениеләрендә, вакытлыча торакларда (җыелма йортларда, палаткаларда, җир асты өйләрендә), шулай

ук сакланып калган торак фонд мәйданында урнаштыру» сүзләрен «вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында» сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Кәримов Марат Ришатовичка йөкләргә.

Башлык А.Ф.Сәлахов